| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 сентябрь г.Казань № 858

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр үзләре кабул иткән карарлар нигезендә 2020 елда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 май, 368 нче; 2020 ел, 6 июль, 551 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр үзләре кабул иткән карарлар нигезендә 2020 елда Федераль казначылыкның

Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исемлегенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 23 сентябрь, 858 нче
карары белән расланды)

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр үзләре кабул иткән карарлар нигезендә 2020 елда едераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исемлеге

| Бюджетара трансферт исеме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүченең исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе |
| Хәрби комиссариатлар булмаган территори-яләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның антлы утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (аңа үзгәреш кертү) буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү өлешендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| 1 | 2 |
|---|---|
| балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү хокукларын тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | |
| Россия Федерациясе субъектларының дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салуларны финанслашу өчен һәм (яки) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт (муниципаль) милкендәге объектларына капитал салуларга карамый торган чараларны финанслашу өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| Авыл территорияләрен комплекслы үстерү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| «2016 – 2020 елларга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасын тормышка ашыру өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| Мәдәният өлкәсенә ярдәм күрсәтү өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Халкы 300 мең кешегә кадәр булган торак пунктлардагы муниципаль театрларның иҗат эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү һәм матди-техник базасын ныгыту өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Модельле муниципаль китапханәләр булдыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |